КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 сентябрь г.Казань № 887

Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен үткәрү буенча эшләр башкару турында булган контрактның шартларына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 августындагы 1315 номерлы карарының 3 пункты нигезендә һәм 2021 елда төзелеш ресурсларына бәяләрнең шактый артуына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен үткәрү буенча эшләр башкару турында булган һәм Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактны (алга таба – контракт) үтәгәндә түбәндәгеләр дип билгеләргә:

а) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты нигезендә бу карарның кушымтасында күрсәтелгән дәүләт заказчысы бер ягы булып торган контрактның мөһим шартларына, түбәндәге барлык шартларны үтәп, үзгәреш кертергә, шул исәптән контракт бәясен үзгәртергә (арттырырга) рөхсәт ителә:

контрактның мөһим шартларына үзгәреш кертү контрактны үтәү срогы эчендә Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә

ашырыла һәм контрактны үтәү срогын һәм (яки) контракт бәясен 30 проценттан артыкка арттыруга китерми;

тиешле капиталь төзелеш объектының проект документациясендә (төзүче яки техник заказчы тарафыннан расланган һәм нигезләрнең, төзелеш конструкцияләренең, инженерлык-техник тәэмин итү системаларының һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең дефектлары исемлеге бирелгән, мондый кимчелекләрнең сыйфаты һәм микъдары ягыннан тасвирнамәләре күрсәтелгән актта һәм төзүченең яки техник заказчының эшләр эчтәлегенә карап проектлауга йөкләмәсендә) каралган эшләрнең физик күләмнәренә, конструктив, оештыру-технологик һәм башка карарларга үзгәреш кертелми;

контракт бәясен үзгәртү (арттыру) күләме – «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2019 елның 23 декабрендәге 841/пр номерлы боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү турында булган контракт сметасын төзү методикасына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 21 июлендәге 500/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә, ә күләме 100 млн.сум тәшкил иткән яки аннан артыграк булган контракт бәясен үзгәртү (арттыру) күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәнең 45 (14) пункты нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтүнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү, мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча эшләр үткәрү өлешендә үткәрелә торган проект документациясенә яңадан дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә;

контрактның мөһим шартларына үзгәреш кертү дәүләт заказчысына тәэмин итүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) контрактның мөһим шартларына әлеге контрактны үтәгәндә кайтартылырга һәм (яки) файдаланылырга тиешле төзелеш ресурсларына бәяләрнең шактый артуына бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү турында язма рәвештә кергән тәкъдим нигезендә дәүләт заказчысы белән тәэмин итүче (подрядчы, үтәүче) арасында контракт шартларына үзгәреш кертү турында килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла, аңа әлеге тәкъдимне нигезли торган документлар һәм мәгълүмат теркәлә;

контракт 2021 елның 1 июленә кадәр төзелгән һәм аның буенча йөкләмәләр контракт шартларына үзгәреш кертү турында килешү төзү датасына үтәлмәгән;

б) контрактны үтәгәндә кайтартылырга һәм (яки) файдаланылырга тиешле төзелеш ресурсларына бәяләрнең капитал салуларны гамәлгә ашыру турындагы актта (карарда) күрсәтелгән капиталь төзелеш объекты кыйммәтеннән артыграк күләмгә кадәр артуына бәйле рәвештә, контракт бәясен үзгәртергә (арттырырга) кирәк булганда мондый үзгәртү (арттыру) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы бюджетыннан акча (мондый ассигнованиеләр файдаланылган очракта) бүлеп бирү турындагы карары кабул ителгәннән соң билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

в) контракт бәясен капитал салуларны гамәлгә ашыру турындагы актта (карарда) күрсәтелгән капиталь төзелеш объекты кыйммәтеннән артыграк күләмгә кадәр үзгәрткән (арттырган) очракта, капитал салуларны гамәлгә ашыру турындагы актка (карарга) үзгәрешләр кертү таләп ителми.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 сентябрь, 887 нче
карарына кушымта

Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен үткәрү буенча эшләр башкару турында булган һәм Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактның бер ягы булып торган дәүләт заказчылары
исемлеге

1. «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;
2. «Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;
3. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе.

___________________________________